**КАРАР**
**Азнакай муниципаль районы**
**Тымытык авыл җирлеге Советы**

**Тымытык авылы** **№ 82-135** **«01» октябрь 2019 ел**

Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Советының 26 апрель 2010ел № 115 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге бюджет процессы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (11.11.2010ел №10, 01.11.2011ел №26, 29.11.2013ел №74-14, 18.08.2014ел №23, 29.10.2015ел №8-3, 28.06.2017ел №47-31, 13.11.2017ел №63-45 крарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)

25.12.2018 ел №494-ФЗ «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлегендә бюджет процессы Нигезләмәләрен Россия Федерациясенең гамәлдәге бюджет законнарына туры китерү максатларында

**карар чыгарды:**

1. Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Советының 26.04.2010 ел № 115 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге бюджет процессы турында Нигезләмәгә (11.11.2010ел №10, 01.11.2011ел №26, 29.11.2013ел №74-14, 18.08.2014ел №23, 29.10.2015ел №8-3, 28.06.2017ел №47-31, 13.11.2017ел №63-45 крарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 18.1 статья өстәргә:

«18.1. Салым чыгымнары исемлеге һәм бәяләү

1. Җирлекнең салым чыгымнары исемлеге муниципаль программалар һәм аларның структур элементлары, шулай ук муниципаль программаларга керми торган эшчәнлек юнәлешләре буенча җирлек Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә формалаша.

2. Авыл җирлегенең салым чыгымнарын бәяләү ел саен, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләрне үтәп, җирлек башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә башкарыла.

3. Әлеге бәяләү нәтиҗәләре җирлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен формалаштырганда, шулай ук муниципаль программаларны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләгәндә исәпкә алына.»;

1.2. 24 статьяның 3-5 пунктларын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирлек бюджеты турында карар проекты буенча килешмәгән сораулар

килеп туган очракта, җирлек Советы Рәисе карары белән килештерү комиссиясе төзелергә мөмкин, аңа җирлек башкарма комитеты һәм җирлек советы вәкилләренең тигез саны керә.

4. Җирлек бюджеты турындагы карар проекты барлык кирәкле документлар һәм материаллар белән җирлек Башкарма комитеты тарафыннан җирлек Советына, эшләп бетерүгә кергәннән соң, өч эш көне дәвамында тәкъдим ителергә тиеш.

5. Җирлек Советы авыл җирлеге бюджеты турында карар проектын бер укылышта карый.».

2. Әлеге карарның 1.1 пункты 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatar.ru. урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай районы Тымытык авыл җирлеге Советының бюджет, финанс, салым һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Э.Х.Гыйләҗева